| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 25 февраль г.Казань № 136

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 27 сентябрь, 1187 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 27 сентябрь, 1187 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 11 июль, 549 нчы, 2025 ел, 23 август, 628 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2025 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга;

1.1 пунктның беренче абзацында «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга;

1.3 пунктта «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы» сүзләрен «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2025 елның 29 ноябрендәге 81-ТРЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктның икенче абзацында «2023 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган» сүзләрен «2024 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктның җиденче абзацында «2027 елның 31 декабре» сүзләрен «2028 елның 31 декабре» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктка «, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

7.9 пунктның икенче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.6 пунктта «субсидияне кире кайтарудан» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтарудан» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада:

нумерация баш исемендә «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга;

исемендә «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтаның нумерация баш исемендә «2025» саннарын «2026» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

2026 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 25 февраль, 136 нчы карары редакциясендә)

Форма

2026 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында гариза

______________________________________________________________________________

(юридик затның тулы исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булганда)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 27 сентябрь, 1187 нче карары белән расланган 2026 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) нигезендә 2026 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан ________________________________________________ сум күләмендә субсидия (алга таба – субсидия) алуга заявка җибәрә (саннар һәм сүзләр белән)

Сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат:

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Заявка бирүченең мәгълүматлары |
|---|---|---|
| 1. | Юридик затның тулы исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булганда) | |
| 2. | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры | |
| 3. | Исәпкә куелу сәбәбенең коды | |
| 4. | Төп дәүләт теркәве номеры, индивидуаль эшмәкәрнең төп дәүләт теркәү номеры) | |
| 5. | Муниципаль берәмлекләр территорияләренең гомумроссия клас-сификаторы | |
| 6. | Юридик затның урнашу урыны / индивидуаль эшмәкәрнең яшәү урыны | |
| 7. | Юридик затның факттагы адресы | |
| 8. | Юридик затны / индивидуаль эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу датасы | |
| 9. | Банк реквизитлары, шул исәптән: | |
| 9.1. | кредит оешмасының исеме | |
| 9.2. | исәп-хисап счеты | |
| 9.3. | корреспондент счеты | |
| 9.4. | банк идентификация коды | |
| 10. | ОК 029-2014 (КДЕС Ред.2) һәм ОК034-2014 (КПЕС 2008) нигезендә икътисадый эшчәнлекнең төп төре | |
| 11. | Телефон, электрон почта адресы | |
| 12. | Сайлап алуда катнашучының җитәкчесе (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда), вазыйфасы, телефоны) | |
| 13. | Баш хисапчы (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), телефон) | |
| 14. | Җаваплы башкаручы (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), телефон) | |

Түбәндәгеләрне раслыйм: ___________________________________________________________

(юридик затның тулы исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булганда)

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм ____________________________ төзегән җиһазлар

(Россия лизинг оешмасының исеме)

лизингы шартнамәсе (шартнамәләре) ____________________________________________________

(лизинг шартнамәсе номер, датасы, җиһазның исеме, җиһазның ОКПДы)

Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның «Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторын (ОКВЭД2) ОК 029-2014 (КДЕС Ред.2) һәм Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча продукция гомумроссия классификаторын (ОКПД2) ОК 034-2014 (КПЕС 2008) гамәлгә кертү турында» 2014 елның 31 гыйнварындагы 14-ст номерлы боерыгы белән расланган Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча гомумроссия продукция классификаторы нигезендә «Эшкәртү производстволары» бүлегенә караган (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы алып бару тармагына карамаган эшчәнлек төрләреннән тыш) эшчәнлекне гамәлгә ашыра һәм субсидия бирү нәтиҗәләренең түбәндәге күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итәргә тиеш:

| Т/с | Нәтиҗәнең исеме | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамаган эшчәнлек төрләреннән тыш, Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре буенча яңа кыйммәт булдыру (яңа төп фондларны гамәлгә кертү, модернизацияләү, реконструкцияләү) хисабына хисап елы өчен төп фондларның тулы исәпкә алу кыйммәтен арттыруны (керүне) (тупланган нәтиҗә белән) («Төп фондларның (акчаның) һәм финанс булмаган башка активларның хәрәкәте булу-булмавы турында мәгълүматлар» дигән 11 нче федераль статистик күзәтү формасының 4 графасындагы 07 нче юлы) бирелгән субсидия күләменә карата нисбәте | | | |
| 2. | Бирелгән субсидия күләменә карата икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча төп капиталга инвестицияләр күләменең нисбәте (тупланган нәтиҗә белән) | | | |
| 3. | Бирелгән субсидия күләменә карата икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча үзләре җитештереп, төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр күләменең нисбәте (тупланган нәтиҗә белән) | | | |

Субсидия бирү нәтиҗәләрен исәпләгәндә кулланыла торган күрсәткечләрнең абсолют кыйммәтләре түбәндәгеләр тәшкил итә:

| Т/с | Күрсәткеч исеме | 2026 ел | 2027 ел | | 2028 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | туплан-ган нәтиҗә белән | шулардан 2027 елга | туплан-ган нәтиҗә белән | шулар-дан 2028 елга |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамаган эшчәнлек төрләреннән тыш, Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре буенча яңа кыйммәт булдыру (яңа төп фондларны гамәлгә кертү, модернизацияләү, реконструкцияләү) хисабына хисап елы өчен төп фондларның тулы исәпкә алу кыйммәтен арттыру (керү) (тупланган нәтиҗә белән) («Төп фондларның (акчаның) һәм финанс булмаган | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | башка активларның хәрәкәте булу-булмавы турында мәгълүматлар» дигән 11 нче федераль статистик күзәтү формасының 4 графасындагы 07 нче юлы), сум | | | | | |
| | шул исәптән: | | | | | |
| 1.1. | 2026 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан сорала торган субсидия бирүгә бәйле | | | | | |
| 1.2. | «Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау» һәм (яки) «Сәнәгать предприятиеләренең яңа җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау» чаралары буенча субсидияләр (субсидияләр) бирүгә бәйле рәвештә субсидияләр (субсидия бирү турындагы килешү нигезендә) | | | | | |
| 2. | Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча төп капиталга инвестицияләр күләме (тупланган нәтиҗә белән), сум | | | | | |
| | шул исәптән: | | | | | |
| 2.1. | 2026 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан сорала торган субсидия бирүгә бәйле | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2. | «Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау» һәм (яки) «Сәнәгать предприятиеләренең яңа җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау» чаралары буенча гамәлдәге шартнамәләр буенча субсидия (субсидияләр) бирүгә бәйле рәвештә (субсидия бирү турындагы килешү нигезендә) | | | | | |
| 3. | Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча үзләре җитештереп, төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр күләме (тупланган нәтиҗә белән), сум | | | | | |
| | шул исәптән: | | | | | |
| 3.1. | 2026 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан сорала торган субсидия бирүгә бәйле | | | | | |
| 3.2. | «Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау» һәм (яки) «Сәнәгать предприятиеләренең яңа җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау» чаралары буенча субсидияләр (субсидияләр) бирүгә бәйле рәвештә субсидияләр (субсидия бирү турындагы килешү нигезендә) | | | | | |

Сайлап алуда катнашу шартлары белән таныш һәм килешәм.

Субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, алынган субсидия суммасын ирекле тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруга ризалыгымны бирәм.

Россия Федерациясе Салым кодексының 102 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә салым серен тәшкил итүче белешмәләрне тапшыруга ризалык бирәм.

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан минем шартларның үтәлешен һәм субсидияләр бирү тәртибен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгымны бирәм.

Субсидия бирүгә гаризада булган мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга ризалыгымны бирәм.

Тәкъдим ителгән мәгълүматларны тикшерүгә ризалыгымны бирәм.

Тәртипнең 5.3 пункты нигезендә түбәндәге документларны терким: ___________________________________________

____________________________________________________________________________________________

Юридик зат җитәкчесе
(индивидуаль эшмәкәр) _____________ ________________________________________________________

(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20 __ ел, «__» _____________

М.У. (булганда)

________________________________